КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 июль г.Казань № 635

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү турында» 2018 ел, 19 гыйнвар, 19 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү турында» 2018 ел, 19 гыйнвар, 19 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 декабрь, 1257 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибенә, 1.4 пунктның уналтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Балаларга һәм яшьләргә тәрбия бирүне һәм укытуны, аларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән СП 2.4.3648-20 нче санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары белән расланган «Балаларга һәм яшьләргә тәрбия бирүне һәм укытуны, аларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән СП 2.3.3157-14 нче санитария кагыйдәләренең 4.5 пункты нигезендә Кулланучылар хокукларын саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә хәбәрнамә;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин